# ЧИШМӘ БАШЫ

“ Туган телне сөючеләр”пресс-центры

Гыйнвар, 2016 ел

№1

## Бу санда

- Иҗат – гүзәл гамь ул
- Ах, бу БДИ! (кушымта)
- Бөек шагыйребез Г.Тукайның тууына – 130 ел
- Ә син белә идеңме?
- Хәбәрчеләребез язмалары
- Суз эчендә хикмәт бар

## Гыйнвар аеның истәлекле даталары



**1 гыйнвар - күренекле татар шагыйре Һади Такташның тууына 115 ел(1901–1931).**



**7 гыйнвар - Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәшировның тууына**
115 ел (1901–1999)



**13 гыйнвар - татар әдәбияты классигы – күренекле прозаик, драматург Фатих Әмирханның) тууына 130 ел** (1886–1926)



### *Гаилә тәрбиясе -милли тәрбиянең нигезе*

*“Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас “*
*Р.Фәхреддин*

Бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып торган милли мәгариф системасын без киләчәк буынны гаилә, балалар бакчасыннан алып, югары мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту буларак күз алдында тотабыз. Һәр мәгариф учреждениесе бүген яңача яшәргә, яңача эшләргә омтыла. Шул уңайдан, укыту процессына Икенче буын дәүләт укыту стандартлары кертү шартларында , һәр коллективтан, һәр укытучыдан рухи һәм физик сәламәт, югары эрудицияле, конкурентлыкка сәләтле, укырга теләге булган, бүгенге тормышта үз урынын таба, максатына ирешә ала торган балалар тәрбияләү өчен төрле гамәли юллар табу сорала.

“Халыкның тормыш тәҗрибәсен, фәлсәфәсен, гореф-гадәтен, фәнен, тарихын, ниһаять, һәрбер халыкның халык булуын мең еллар буенча саклап килүче бетмәс-төкәнмәс бер байлыгы бар. Ул – аның теле”,- дип язган күренекле якташ язучыбыз **Гомәр Бәширов**. Шушы шартларда “бетмәс-төкәнмәс бер байлыгыбыз” булган туган телебезне замана тудырган сикәлтәләрдә таралып югалмасын өчен, белем бирү учреждениеләрендә ничек укытырга соң? Әлбәттә, бу юнәлештә татар теле һәм әдәбияты укытучылары максатчан эш алып баралар. Яңа эш формаларын һәм методларын кулланып эшләүгә, уңышлы алымнарны эзләүгә һәм куллануга әһәмият бирәләр. Мәктәпләрдә узган семинарларда укытучылар татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә мәгълүмати, инновацион технологияләр куллану, профильле укыту, сәләтле балалар белән эш, концентрлы укыту прблемаларын күтәрәләр. Укытучы хезмәтенең төп күрсәткече- укучының белем дәрәҗәсе. Яңа буын укыту стандартлары таләп иткәнчә, укытучы хәзер укучыларны “энә белән кое казырга” өйрәтергә тиеш.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: тел- милләт сакчысы ул. Шуңа күрә балаларыбызга безнең иң изге бурычларыбызның берсе булган телебезне, әдәбиятыбызны өйрәтү, аларны тарихыбызның, мәдәниятебезнең, сәнгатебезнең энҗе- мәрҗәннәре белән таныштыру процессы гаиләдә туган телебезгә формалашкан уңай караш белән бергә үрелеп барса, мөһим эшебезнең нәтиҗәсе әйтеп бетергесез зур булачак.

**Арча мәгариф идарәсенең милли мәсьәләләр буенча методисты Э.Г. Мостафина**



## Суз эчендә хикмәт бар

- Бәхетле чагында - сабыр, хәсрәт килгәндә акыллы булып кал. (Периандр)
- Һәрвакыт вакыты юклыкка зарланучылар, гадәтә, бернәрсә дә эшләмиләр. (Георг Кристоф Лихтенберг)
- Үз-үзеңне хөрмәт ит, һәм сине башкалар да хөрмәт итәчәк. (Александр Дюма)
- Ахмакларга бер җавап бар - дәшми калу. (Унсур әл Маали)
- Акыллы кеше аздан гына да бәхетле, ә ахмакка һәрвакыт җитми, шуңа күрә бик күп кешеләр бәхетсез. (Франсуа де Ларошфуко)
- Җанына тынгы тапмаган кеше беркайчан да тынычлык таба алмый. (Франсуа де Ларошфуко)
- Киңәш бирергә була, ләкин шул киңәшне куллану өчен акыл биреп булмый. (Франсуа де Ларошфуко)
- Мәгънәсез сүзгә караганда иярсез ат ышанычлырак. (Феофраст)

## Тукай абый әкиятләре

Тукай абый әкиятләрен
Бик яратып укыйбыз
“Таз малае”н, “Су анасы”н
Сәхнәләрдә уйныйбыз.

Кызыгабыз Тукай йөргән
Урманнарда йөрергә
Озын бармак, зур мөгезле
Шүрәлесен күрергә.

***Сәмигуллина Зөлфия, 7 класс***
***Хәсәншәех төп гомуми белем мәктәбе***



## Шаянворд

### *Ял сәгатьләрендә*

**Горизонталь буенча:** 4. Чүпрәкне кырыеннан атлатып тегү. 8. Өйрәнеп барлыкка килгән осталык, тәҗрибә. 9. Хатын-кыз күлмәгенә тегелә торган өчпочмаклы тукыма кисәге. 10. Бетләүнең фәнчә атамасы. 11. Кушылган эшне үтәргә риза булганда шулай диләр. 12. Буй-буй тиреле, ал һәм арт аяклары арасында киң ярылы җәнлек. 14. Эстрадасы булган кафе. 17. Көньяк Уралдагы шәһәр (анда алтын чыгаралар). 18. Төньяк Кавказдагы республика. 21. Пиреней тауларында урнашкан кечкенә дәүләт. 22. Үткен исле сыеклык, эреткеч матдә. 24. Ир белән хатын булуны рәсми теркәү. 25. Иң беренче кеше (динчә).

**Вертикаль буенча:** 1. Киләчәкне алдан белгән атлы булып кәсеп итүче. 2. Зур томшыклы су кошы (баба кошы да диләр). 3. Гәүдәнең берәр әгъзасын кисеп ташлау. 5. Бозауның атасы. 6. Нәрсә дә булса ясау өчен булган әйбер, матдә, чимал. 7. Ток чыганагын кулланучыга ялгый торган чыбык 9. Затлы тиреле җәнлек. 13. Яшь ат. 14. Каен үсә торган урын, каен урманы (ләкин күбрәк зиратны шулай атыйлар). 15. Вак кисәкләрдән тегелгән (яки ясалган) нәрсә. 16. Туфрактагы органик катнашмалар. 17. Савыттан сыеклык агызып ала торган көпшә. 19. Музыка коралы. 20. Кызны кияүгә алу турында аның ата-анасы белән килешү. 23. Дөньяда иң озын елга.




## Кар бөртеге

Талгын гына, салмак кына әйләнгәләп,
Кар бөртеге үзенә төшәр урын эзли.
Төшкән чакта кызыксынып,тирә-юньне,
Ап-ак бәсле табигатьне, җирне күзли.
Уйлый үзе: миңа җирдә ничек булыр ?
Күпме икән минем якын дуслар булыр?
Дуслар белән бергәләшеп уйнаганда,
Юлчыларга караңгы төн дә якты булыр.

Гарифуллина Чулпан
Г. Тукай исемендәге Ашытбаш урта мәктәбенең 5 нче сыйныф укучысы

**Газетаны оештыручы һәм баш редактор:**
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
**Әүхәдиева Миләүшә Рәшитовна**
**Редколлегия әгъзалары: Сабитова Т., Фәйзиева А., Нуриева Т., Абдуллина Э.**

**Индекс-** 422000
**Тираж-** 100 данә

**Адрес:** ТР,Арча шәһәре, Вәгыйзовлар урамы, 11
Арча муниципаль районы”Арча мәгариф идарәсе”

# Ах, бу БДИ!!!

**Ашытбаш мәктәбе укучылары яза**

( укучылар һәм укытучылар белән әңгәмәне Чулпан Мөхәммәтдинова уздырды)

**11 еллык могҗиза яки чыгарылыш укучылары белән әңгәмә**



Безнең Арча районында күп яктан үрнәк булырлык мәктәпләр күп. Бүген мин шулар исемлегендә булган Г. Тукай исемендәге Ашытбаш мәктәбенә юл тоттым.Мәктәп каршында ук мине бер көтү яшүсмер чолгап алды. Болар- чыгарылыш сыйныф укучылары.Әйдәгез, алар белән якынтанрак танышыйк әле.

**-Сәлам, егетләр һәм кызлар! Күрәм сездә кызу урак өсте?**

Энҗе: “Ооо, ничек кенә әле!”

**Могаен, чыгарылыш сыйныф укучыларының 100 кат сандыкта бикләп йорткән серләре, башкалар белеп бетермәгән яңалыклары күптер.Бәлки, мәктәп еллары турында сөйләшеп алырбыз?**

Инсаф: “Сөйләшү, әңгәмә дигәндә без дүрт куллап риза!”

**-Әгәр сезнең сыйныфтагы дусларыгызны 5 балл белән бәяләп булса, нинди балл куяр идегез?**

Инсаф:” 6+! Билгеле, кайвакыт аңлашылмаучанлыклар килеп чыга, ләкин без аларны тиз арада эретеп юкка чыгарабыз.”

**-Әгәр класс җитәкчегезне һәм классташларыгызны сайлап алу мөмкинлеге тудырылса нишләр идегез?**

Мәрьям:” Берни үзгәртмәс идем. Үземне алардан башка күз алдына да китерә алмыйм. Дөрес, кайвакыт ачуны чыгаралар, ләкин 5 минут үтүгә, сагына ук башлыйм.”

**-Айсылу, син 11 ел дәвамында моңлы тавышың белән безне хыял диңгезләрендә йөздерденң.Әгәр Евровидение бәйгесендә катнашырга чакырсалар, нинди җыр башкарың иден?**

Айсылу:

-Җырымны укытучыларыма багышлар идем. Алар миңа һәрвакыт ярдәм иттеләр, тормышта үз юлымны табуга зур өлеш керттеләр.Болай булгач, авылдашыбыз шагыйрь Наил Касыймовка шалтыратмый булмас. Җырның сүзләрен аннан да оста иҗат итүче табылмас, минемчә.

**- Әгәр вакыт машинасы белән идарә итү мөмкинлегең булса, ничәнче елга кире кайтыр иден?**

Наил:

-2005 нче елның 1 нче сентябренә кайтыр идем. Мәктәпнең якты бинасына сокланып йөргәннәрем әле дә исемдә.Аннан китте инде: яңа дуслар, кызыклы вакыйгалар...Эх, бер мизгелгә генә кайтарасы иде ул көнне!

Айсылу сөйләгән укытучылар белән үземнең дә танышасым килде.Кыю адымнар белән мәктәпкә юнәлдем.Ишек төбендә үк мине көләч йөзле укытучылар каршы алды.

**- Исәнмесез! Әле генә сезнең мәктәпнең чыгарылыш сыйныф укучылары белән очраштым, алар турында ни әйтер идегез?**

Әлфия Әхмәтгалиева:

- Мәктәбебездә талантлы балалар укый дисәм дә ялгыш булмас. Быелгы 11 нчеләр спорт өлкәсендә дә, иҗат юнәлешендә дә беренчелекне бирмиләр.Шаянлыклары гел үзләре белән , ләкин чама хисен дә югалтмыйлар.

**Рәсилә Рәүфовна, быелгы 11 нче класс укучылары арасыннан кемне аеруча якын итәсез?**

Бик авыр сорау булды бу.Укучыларымның һәммәсе дә якын миңа.7 ел алар белән эшләү дәверендә үзләрен бары яхшы яктан гына күрсәттеләр.Һәрчак гадел, мөстәкыйль, ярдәмчел була белделәр.

**Рәмизә Рәисовна, сез 2016 нчы елдан ниләр көтәсез?**

2016 нчы елгы чыгарылыш сыйныфына алмашка үзләре кебек үк уңган һәм тырыш укучылар килүен көтеп калам.Киләсе елның уңышлы булачагына чын күңелдән ышанам.

Кадерле укытучыларыбыз!Газета битләре аша сезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.11 ел дәвамында сез безне тирән белем иле белән генә таныштырып калмадыгыз, тормышта үз урыныбызны табарга, каршылыклар алдында баш имәскә дә өйрәттегез.Сезгә авыр эшегездә уңышлар, сәламәтлек, гаиләләрегездә иминлек, тыңлаучан һәм белемле укучылар телибез.



**Укытучылар киңәште**

21 нче гыйнвар көнне Шушмабаш урта мәктәбе базасында БРТна әзерлек буенча татар теле һәм әдәбияты укытучыларының зона семинары узды. Шушмабаш урта мәктәбендә заман таләпләренә туры килә торган һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Килгән кунаклар мәктәбебез директоры Шаймарданова Р.Г. чыгышы аша да моңа инандылар.Гамәли семинарда Арча мәгариф идарәсенең милли мәсьәләләр буенча методисты Мостафина Э.Г. укытучылар алдын да торган бурычларга тагын да җитди карарга кирәклеген ассызыклады.

Методистның чыгышыннан соң Шушмабаш урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сабитова Т.Ә.чыгышы тыңланды.Ул үзенең БРТ на әзерлек планы нигезендә мәктәптә системалы эшнең башкарылуы турында чыгыш ясады.Һәр килгән укытучы имтиханнарга әзерлек буенча үзенең эш тәртибе белән таныштырды. Үзара ярдәмләшү максатыннан һәр айның 4 нче числосын да башка мәктәпләргә барып, сынау эшләре алу планлаштырылды.

Гамәли семинарда һәр укытучы үзен борчыган сорауга җавап алды. Семинардан укытучылар киләчәктә дә шушындый эшлекле сөйләшүләр күбрәк булуын теләп таралыштылар.

**Сабитова Т. Ә. татар теле һәм әдәбияты укытучысы**



## Син һәм ул: БДИ

Ул инде ерак түгел. Ул һәм син. Син һәм ул. Күп тә үтмәс, сез күзгә күз очрашачаксыз. “Уян! Бу нибары куркыныч төш!” , ди синә йөрәгең, тик баш миең әледән-әле йөрәгең белән сүзгә килә. “Бу төш түгел, бу чынбарлык! Бу куркыныч чынбарлык!”. Әйдә, дустым, йөрәк белән баш миеңне дуслаштырып карыйк бүген. Алар икесе киңәшеп эш иткәндә генә барлык хыяллар тормышка аша бит. Ә сүзебез бүген син” яраткан “БДИ турында барачак. Йә, йә, өйдә дә, мәктәптә тә, тагын монда да шул дип бу битне ябарга ашыкма. Мин ышанам, син булдыра алмаган эш юк бу дөньяда!

Әгәр дә син 11 нче сыйныф укучысы икән, син инде азмы-күпме нинди фәннәрдән имтихан тапшырачагыңны уйлап йөрисеңдерер. “Юк. Мин үземнең кая барырга теләвемне дә, нинди имтихан бирәчәгемне дә белмим. Һәм белергә дә теләмим!” дисеңме? Курыкма, бу - нормаль күренеш. Чыгарылыш сыйныф укучыларының күбесе нинди фән сайларга белми аптырый. Һәм бу аптырау бик озакка да сузылырга мөмкин. Нинди фәннәрдән имтихан тапшырачагыңны ачыклау – синең имтиханга әзерлегеңнең иң мөһим баскычы. Шуңа киләсе киңәшләрне игътибар белән укуыңны үтенәм:

1.Нинди фәннән имтихан тапшырачагыңны билгеләү җайлы. Хәтта син ул фәннән имтиханны да уңышлы тапшырырга мөмкинсең. Тик аннан теләмәгән җиреңә укырга кереп, үкенерлек булмасын.

2.Ә менә хәзер йөрәгең белән башыңны түгәрәк өстәл артына “утырт” та, тәмле чәй артында “сөйләштер”:

-Ни белән син чын-чынлап кызыксынасың? ( вакытлыча түгел!);

-Әлбәттә, әти-әни белән киңәшләшү кирәк нәрсә. Тик бер кайчан да, ишетәсеңме, беркайчан да әти-әни шулай теләде дип, үз хыялларыңнан баш тартма. Аннан үкенерлек булмасын. Әгәр дә син бу каршылыклар белән бүген үк очрашкан сың икән, аларга үзеңне нәкъ менә шул өлкәдә күрүеңне аңлатырга тырыш. Чөнки соңыннан, инде укырга кергәч, сиңа гына түгел, әти-әниеңә дә синең яратып укымавыңны күрү авыр булачак.

3.Имтихан көне үзен озак көттермәс. Тик бу стресска бире шергә , ашау-эчүдән, йокыдан калырга дигән сүз түгел. Әти-әниең синең уңышлы белем алуың өчен бар мөмкинлекне тудырды, бар укытучылар син белсен дип күп көч түкте, ниһаять, син үзең 11 ел буе белем дигән каты гранитны кимердең. Шушылардан соң ул башыңда ни дә булса калгандыр бит инде? Бирәсең, Алла боерса, бары ышан гына. Исеме куркыныч яңгыраса да, үзе алай үк куркыныч түгел ул. Уңышлар, дустым!

КФУның 2 курс студенты Зилә Сабитова



## Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туууына 130 ел



### Укучылар фикере

- ...“Минем беренче ишеткән әкиятләрем Тукай абый әкиятләре иде. Балалар бакчасында ук аның шигырьләрен, җырларын өйрәндек, әле дә яратып укыйбыз. *(Сәмигуллина Азалия ,4 сыйныф)*
- ...“Габдулла Тукай зурлар өчен дә, балалар өчен дә күп әсәрләр язган. Аның балачагында күргән авырлыклары турында мин бик дулкынланып укыдым.” *(Әхмәтова Гөлшат,8 нче сыйныф)*
- ...Шагыйрьнең һәр шигыре безнең җаннарыбызга рухи сафлык индерә, тормышта яшәргә өйрәтә.*(Мәҗитова Энҗе . 11нче сыйныф)*

**Тукай абыйга!**

Тукай абый! Балачагымнан ук
Синең җырларыңны тыңладым.
Бишек җырың тыңлап,“Туган тел”не җырлап,
Ачылгандыр минем телләрем.
Хәтерлимен , караңгы төннәрдә
Әниемнең әкият укуын.
Хәтерлимен, синең Шүрәлеңнән,
Җен- пәриләреңнән куркуым.
Төннәрендә җилләр тәрәз какса,
Су анасы диеп шомландым.
Бары әни кочагында гына
Бернинди дә борчу тоймадым.
Җен-пәриләр, Шүрәлеләр юк ул!
Шагыйрәнә ялган бит алар.
Син әйткәнчә, күп укыса гына,
Аңлый ала моны балалар.
Кырлайдагы кебек серле урман
Безнең якларда да җитәрлек.
Авылым табигате, кешеләре
Сокланырлык, исең китәрлек.
Синең кебек мин дә ,Тукай абый,
Туган авылымны яратам.
Менә бүген, синең бәйрәм көндә,
Сиңа хөрмәтемне аңгыратам.

***Нуриева Гөлнур ,10 нчы сыйныф***

**Туган авылым**

Яратам мин туган авылымны
Челтерәп аккан чишмә суларын.
Матур болыннарын, урманнарын,
Иксез-чиксез иркен кырларын.
Алтын башак тулы басуларын,
Су буенда үскән камышын.
Биек тауда татлы җиләкләрен,
Көзге яфракларның тавышын...
Шундый матур туган авылымны
Сагынып кайта һәрбер баласы.
Китә алырмынмы авылымнан?
Юктыр!Анда килә мәңге каласы!

**Чын дустым**

Кайчакларда төшенкелек биләп
Алган чакта минем күңелне.
Янәшәмдә һәрчак син буласың,
Табасың син җылы сүзеңне.
Шатлыкны да, авырлыкларны да
Синең белән, дустым, бүлешәм.
“Чын дус бирәү генә була “,-диләр.
Бу сүз белән мин дә килешәм.

***Закирова Эльвира 8 нче сыйныф***

**Гата**

Беркөн китте безнең Гата
Мәктәпнең бакчасына.
Билгеле инде:калдырмады
Үзенең букчасын да.
Эшләргә дип әйтәсездер.
Алай түгел, һич түгел.
Чөнки аның эшләргә
Куллары бит буш түгел.
Куллары белән алманы
Букчасына тутыра.

Авызына да приказ бирә:
“Тизрәк аша, тик торма!”
Тамак туйды,кесә тулды.
Хәзер кирәк таярга.
Бәлки әле өлгереп булыр
Берaз кыяр җыярга.
Чү, тукта әле,ни булды?
Гата каты кычкыра.
Бал корты чаккан иренен
Елый малай, котыра.

Ә бал корты әйтә аңа:
- Эшләмәгән ашамый!
Яхшы кешеләр тормышын
Мондый юлдан башламый.
Ә син, Гата, төзәл әйдә,
Бүтән алай эшләмә!
Ә иртәгә кил син әйдә
Бу бакчада эшләргә.

***Ибрагимова Энҗе,***
***7 нче сыйныф***



# Мәктәп сулышы

**“Яшьлек” иҗади коллективы 10 мең сумлык призга лаек булды.**

Агымдагы уку елында Апаз урта мәктәбенең Ибраһимова Римма җитәкчелегендәге “Яшьлек” иҗади коллективы (Галиев Ришат, Миннебаева Энҗе, Ибраһимова Зөһрә, Мәҗитова Энҗе) Республикада үткәрелгән “Бала хокук даирәсендә” иҗтимагый-мәгълүмати видеороликлар конкурсының “Тамашачылар мәхәббәте” юнәлешендә 10 мең сумлык призга лаек булды.

Алар бүләкләү тантанасында катнашып, Татарстан Республикасы буенча бала хокукларын яклаучы – Удачина Гүзәл Любис кызы кулыннан 10 мең сумлык сертификатны алып кайттылар. Аларга алдагы көннәрендә дә иҗат уңышлары телибез.

***Эльвира Закирова,***
***8 нче сыйныф*, Апаз урта мәктәбе.**

**Күңелле мәктәп тормышы**

“Хәрәкәттә-бәрәкәт” дип юкка гына әйтмәгәннәр. Шуңа да укучылар физкультура дәресләрен зур түземсезлек белән көтеп алалар. Теннис командасы күп еллардан бирле районда беренчелекне алып килде, хәзер дә команда беренчелекне бирми.Кыш житү белән һәркем чаңгыга баса. Баскетбол, волейбол, хоккей ярышлары беркемне дә битараф калдырмый. Гадәттә, физкультура дәресен егетләр ярата. Мәктәпкә физкультура укытучысы булып Рифат Рәхимҗанович килгәннән бирле, кызлар да спортны ярата башлады. Ул 2013 нче елдан бирле бирeдә эшли. Рифат Рәхимҗанович- үз эшенең остасы. Бу уку елында ике укучысы район олимпиадасында призер булды. Тиздән Казанда булачак республика олимпиадасына әзерләнәләр.

**Нуриева Тәнзилә , Хәсәншәех мәктәбе укытучысы**



**Әдилә белән горурланабыз.**

Апаз урта мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы Галәутдинова Әдилә- спорт буенча бик көчле кыз. Бу уку елында гына да Әдилә, район призлы урыннар алып, өч медаль иясе булды, ә барлык медальләре 20гә якын. 2015-2016 нчы уку елында көзге кросстан 2 нче урын, кул көрәшеннән 1нче урын, ГТО фестивалендә (4 баскыч) 1нче урын яулады. Без Әдилә белән бер мәктәптә укуыбызга бик шатланабыз, аннан үрнәк алабыз.

***Ленара Әхмәтова, 10 нчысыйныф.***

**Апаз урта гомуми белем мәктәбе укучысы Энҗе Миннебаева Татарстан Республикасы Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең Арча муниципаль районы буенча 2015-2016 уку елына иҗтимагый ярдәмчесе булды.**

Ноябрьдә узган Бөтендөнья Бала хокукларын яклау көнендә Казанда “Балалар иҗтимагый кабул итү көне” дигән республика проектының рәсми рәвештә ачылышы узды. Әлеге яңа проект Татарстанда яшәүче балалар, яшүсмерләрнең хокукларын яклау һәм тормышка ашыру өчен булдырылган. Бу проектта катнашучылар вәкаләтле вәкилнең җәмгать ярдәмчесе статусын алды, алар үз районнарында балаларны кабул итүләрне оештыра, бала хокукларын яклау буенча аңлату эшләре алып бара.

***Гөлзирә Гарифуллина, 11 нче сыйныф***

**Пешәнгер башлангыч мәктәп-балалар бакчасында** яңа ел алдыннан ясалган кар сыннары искиткеч матур килеп чыккан иде. Өч метрдан артык биеклектәге 2016 нчы ел символы Маймыл гына ни тора! Ә ишек алдындагы Шүрәле, аты белән Былтыр, Су анасы, Кәҗә белән Сарык сыннары әкият илен хәтерләтте. Тырышлыгыбызның нәтиҗәсе дә озак көттермәде. 31 декабрь көнне Арча шәһәре стадионында узган тантанада мәктәп-бакчабыз коллективына 3 дәрәҗә диплом һәм кыйммәтле бүләк тапшырылды.

**Педагог-оештыручы Галәветдинова Рания**

*Җылы хисләр*



23нче гыйнварда “Казан арты” тарих-этнография музеенда Арча үзәк китапханәсе каршында эшләп илүче “Каурый каләм” иҗади берләшмәсенең Шигъри тәлгәшләр” исемле китабын һәм “Гариф Ахунов исемендәге әдәби премия лауреатлары” табын тәкъдир итү кичәсе булды. Кичәдә ташыбыз Рифат Җамал да катнашты. Ул, әттәгечә, үзенә генә хас оста юмор теле белән, яшьләргә тәрбия бирерлек чыгыш ясады. Кичә ахырында элекке укытучыбыз, хәзерге вакытта Бөтендөнья татар конгрессының чит ил татарлары белән хезмәттәшлек итү бүлегендә эшләүче Мәҗитова Гөлшат белән очраштык. Ул Носы мәктәбен җылы хисләр белән искә алды. Бу очрашуда безнең мәктәптән Гариф Ахунов исемендәге әдәби премия лауреаты 8 нче класс укучысы Алия Романова катнашты.

Чулпан Латыйпова, Носы төп мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы

*Милләтемнең кояшы син, и моңлы, нурлы Тукай*

Мәктәбебездә “Милләтемнең кояшы син, и моңлы, нурлы Тукай!” баш астында башлангычлар атналыгы башланды. 25 нче гыйнвар көнне атналык кысаларында классларда Габдулла Тукайның 130 еллыгына карата әңгәмәләр үткәрелде. Әңгәмә барышында укучылар Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында белемнәрен ныгыттылар, җырларын җырладылар, шигырьләрен сөйләделәр.

Атналык кысаларында рәсемнәр конкурсы игълан ителде. Укучылар Габдулла Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр ясадылар.



Зилә Нигмәтҗанова, 9 нчы сыйныф укучысы

*Без булдырабыз*

23 гыйнвар көнне Иске Кырлайда укучылар арасында чаңгы ярышлары үтте. Носы мәктәбе данын Миннебаев Илсаф, Заһидуллина Инзилә, Ярullина Эльмира, Самигуллин Рафил, Заһидуллин Гамил яклады. Укучылар, ярышта уңышлы чыгыш ясап, командалар арасында III урынга лаек булдылар. Аларны уңышлары белән чын күңелдән котлыйбыз! Афәрин, укучылар!



Инзилә Заһидуллина, 7 нче сыйныф укучысы

*Талантларны барлар чак*




Укучыларыбыз Балтач районы Кенә төп гомуми Белем мәктәбендә үткәрелгән Римма Ибраһимова исемендәге “Талантларны барлар чак” районара ачык конкурс-фестивальдә катнаштылар. Мәктәбебезнең 8 нче класс укучысы Романова Алия нәфис сүз номинациясендә беренче дәрәҗәдәге дипломга, 4 нче класс укучысы Егорова Алинә шулай ук нәфис сүз номинациясендә икенче дәрәҗәдәге дипломга лаек булдылар.

Инсаф Әхмәтов, Носы төп мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы



# Иҗат - гүзәл гамь ул

Иҗат - гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык ул. Иҗат ике канатлы ул: яхшыны исбат итү, яманны инкар итү ул, яхшылыкка мәхәббәт, яманлыкка нәфрәт ул!
(Хәсән Туфан).

Намуссызлык, битарафлык, кебек күренешләр чәчәк аткан бер вакытта балаларыбызда матурлык идеалы, иҗатка мәхәббәт тәрбияләү актуаль мәсьәлә булып тора. Мин эстетика белгече түгел, шулай да ана теле һәм әдәбияты укытучысы, сыйныф җитәкчесе һәм әни кеше буларак, бу өлкәдә кайбер фикерләрем белән уртаклашасым килә.

Эстетик тәрбия идеалы дигәндә, мин халык иҗаты белән танышу, җыр һәм музыкага, биюгә өйрәтү, табигатьнең матурлыгын бәяләү, аны күрү, тою күнекмәләрен күздә тотам. Күпмедер дәрәҗәдә тышкы матурлыкка ия булып та, эчке дөньясы гүзәллектән, матурлыкны тоя белүдән, гамьнән мәхрүм кешеләргә карата юкка гына ирония белән: “Тыштан ялтырый, эчтән калтырый” димиләр. Кеше тумыштан ук җимерү түгел, матурлык тудыру, иҗат итү сәләте белән туа. Укучыларыбыз арасында иҗат дәрте белән янучы, матурлык иҗат итәргә сәләтлеләр шактый. Әдәби әсәр укырга яраткан, шигырь язган бала нечке күңелле, мәрхәмәтле булып үсә, ул начарлык эшләми, башкаларны кыерсытмый Шигырь, әкият, хикәя язган баланың теле дә сафрак, чистарак, образлырак була. Иҗат гаме белән янган балалар күбрәк булсын иде.

Г. Тукай исемендәге Ашытбаш урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Миләүшә Әүхәдиева .





**Тукайга**

Әкиятләрең, шигырьләрең белән,
Моңлы сазың белән караттың
“ Әллүки”ең белән татар телен
Дөнья илләрендә яңгыраттың.
Туры сүзле Тукай була белдең,
Зирәк җавап таптың дошманга.
Акыллы һәм төпле киңәш бирдең,
Якын булдың газиз дусларга.
Кыска гына шушы гомереңдә
Яшәдең син милләт, халкым дип,
Үзеңнән соң килгән буыннар да
Әйтә сине : “ Безнең шагыйрь” ,-дип.

*Г. Тукай исемендәге премия лауреаты Химамиев Булат,9 нчы сыйныф укучысы, Ашытбаш урта мәктәбе*

**Туган тел**

Туган телем бик матур тел,
Ул була татар теле.
Атам- анам сөйләменнән,
Бишектән миңа керде.
Гаиләм биргән иман нурын
Бары шушы тел аша.
Үз илендә һәрбер милләт
Туган телдә аралаша.
Гасырлардан- гасырларга
Килгән ул, югалмаган.
Һәрбер телне үз халкына
Аллаh үзе юллаган.
Тик көннән- көн азая бит
Туган телдә сөйләүче
Бишек җырын үз телендә,
Туган телдә көйләүче.
Сандугачка да килешмәс
Җырласа ул күкечә.
Сөйләшик без туган телдә
Татарча, үзебезчә.

*Гатауллина Фаягөл, 8 нче сыйныф укучысы, Ашытбаш урта мәктәбе*

## *Бөек шагыйрь Г.Тукайның тууына 130 ел*

***"Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш"(Г.Тукай)***

Шушмабаш мәктәбенә 1923 елда нигез салынган. Ул инде 93 ел укучыларга белем һәм тәрбия бирә. Шул вакыт дәвамында укытучылар коллективы үзенең хезмәтенә тугры булып,күренекле шәхесләр, мәгърифәтчеләр ижатын өйрәтү аша укучыларга ныклы белем һәм тәрбия бирә, аларга олы тормышка юл күрсәтә.Шулай ук мәктәптә якташ шагыйребез Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүгә зур игътибар бирелә.Укучылар елдан- ел аның иҗаты серләренә тирәнрәк төшенә. Шагыйрьнең тууына 130 ел тулу уңаеннан ,мәктәбебездә "Тукайның "эш агачы" ясалды. Ул Тукай исеме белән бәйле конкурсларда катнашып ,җиңү яулаган укучыларның исемнәре язылган "яфраклар " ,"җимешләр"белән бизәләчәк.Агачка берничә тапкыр "Тукай уку"ларында катнашып җиңү яулаган,районыбызның Тукай исемендәге премиясе лауреаты булган Сабитова Зиләнең исеме урын алды.Агачыбыз җимешләрдән сыгылып торсын иде

***Самигуллина Айгөл, 10 нчы сыйныф***

***(Газетабызның 5 битендә Тукай исемендәге премия лауреаты Сабитова Зиләнең мәкаләсе урнаштырылды.)***



### Мәктәбем белән горурланам

Кулыма чәчәк бәйләме тотып, тәүге тапкыр мәктәпкә баруым бүгенгедәй күз алдымда. Шаян сыйныфташларыма, мөлаем укытучы апама бик тиз ияләндем . Шушмабаш мәктәбенә 1923 елда нигез салынган. Ул инде 93 ел укучыларга белем һәм тәрбия бирә. Бүгенге көндә мәктәптә 169 укучы белем ала. Беренче ка рашка безнең мәктәп башка мәктәпләрдән, бәлки, аерылмыйдыр. Әмма монда күңелгә үтеп керә торган җылылык һәм ниндидер рәхәтлек бар. Безнең Шушмабаш мәктәбе районда иң яхшы һәм матур мәктәпләр рәтендә йөри. Ул игелекле һәм тәҗрибәле укыту чыларга, тырыш һәм мөлаем укучыларга бай. Мәктәбебездә бе лем алу өчен барлык шартлар да тудырылган. Күптән түгел уздырылган капиталь төзекләндерүдән соң белем учагыбыз тагын да матурланды. Анда якты сыйныф бүлмәләре, уңайлы ашханә, зур спорт залы, чишенү бүлмәсе, актлар залы, укытучылар бүлмәсе урнашкан. Сыйныф бүлмәләре дәрес өчен кирәкле материаллар белән тулыландырылган. Мәктәбебез төрле олимпиада - конкурсларда, спорт белән бәйле төрле ярышларда да актив катнаша, алдынгы урыннарга ирешә. Бу – безнең укытучыларыбызның һәм укучыларыбызның тырышлыгы нәтиҗәсе.Мин мәктәбем белән бик тә горурланам. Аның киләчәктә тагын да яңа үрләр яулавын теләп калам.

Һадиева Рамилә,5 нче сыйныф

# Ә син белә идеңме?

### Г.Тукайның әдәби кушаматлары (псевдонимнары)

**Тукайның 63 әдәби кушаматы бар. Шуларның кайберләре:**

- Адвокат
- Айнук Самакай малае
- Берничә кешеләрнең үтенече буенча вәкил – Уральск кешесе
- Бер фикерче
- Биик усал
- Имам Хатыйб
- Имзасыз да Ярарс
- Имза: Шәп кеше
- Ишан кирамәт
- Каз.
- Кырмыска.
- Каилел-хак
- Милләтче
- Мин язмадым.
- Мылтык.
- Мәкәрҗәдә булучы
- Мәхүп прахут конторщигы



### Г.Тукай исемендәге премия лауреатлары

Иң яшь лауреат – халык шагыйре Равил Фәйзуллин. Аңа "Шигырьләр һәм поэмалар" китабы өчен премия 35 яшендә бирелгән. Иң өлкән яшьтә алучы – язучы Гомәр Бәширов. Ул премиягә 94 яшендә лаек булган. 90 нан өскә чыккач алган башка берәү дә юк.



## *Шушмабаш урта мәктәбе укучылары иҗаты*

### Кыш бабайны көткәндә

Ап-ак бураннар белән
Авылыма кыш килде.
Күршебезнең бакчасына
Бик матур тау өелде
Өебез тәрәзәсенә
Кыш бабай рәсем ясый.
Җәяүле буран сибереп
Басулардан кар ташый
Өй янындагы зур тау да
Үскәннән үсә бара.
Безнең тауда чана шуып
Шау килә бала-чага.
Яңа елга күп калмады
Кыш бабай нишли икән
Боланнарын җигеп куеп
Бүләкләр төйи микән.
Биек таудан шуа-шуа
Кыш бабайны көтәбез.
Ул килгәнче матур җырлар
Шигырьләр өйрәнәбез.

**Нуриева Кадрия,8 нче сыйныф**

### Җиңү таңы

Язгы иртә.Күктә кошлар сайрый,
Май кояшы җиргә елмая.
-Җиңү килгән,сугыш беткән,-диеп
Шау-гөр килә халык, шатлана.
Бит алмасы буйлап тәгәрәшә,
Кайнар күз яшьләре аларның.
Көннәр-төннәр буе капка ачып,
Көтте алар газиз җаннарын.
Кемнең ире, кемнең улы бүген
Җиңү алып кайтты авылга.
Хәл белергә күрше- күлән керә,
Коймак пешә майлы табада.
Күпме газиз җаннар ятып калды,
Тән ярасы алды күбесе.
Йөрәк әрни, йөрәк сыкрый һаман
Маңгай сыры тирәнәя төсле.
Ул көннән соң күпме михнәт,
Күпме газап артта калды.
Яралар да төзәтелде,
Борчулар да онытылды.
Тынычлык һәм бәхет кошы-
Ак күгәрчен һаваларда.
Куркытмагыз, очсын алар,
Җиңү теләп галәмнәрдә.

**Әсәдуллина Алия,6 нчы сыйныф**

## Әкиятне үзебез язабыз

### Килешләр турында әкият

Борын-борын заманда яшәгән, ди, булган, ди, алты туган. Болар үсә төшкәч, үзләренә исемнәр уйлый башлаганнар. Иң олысын баш итеп куйганнар. Аның исеме Баш булган. Икенчесе, ияге озын булганга – Иялек. Өченчесе кунакка йөрергә яраткан. Анысына Юнәлеш дип исем биргәннәр. Дүртенчесе табигатьнең явым-төшемнәрен күзәтергә ярата икән, шуңа күрә аңа Төшем дигәннәр. Бишенчесе төрле чыгышлар әзерләнү белән шөгыльләнгән. Аның исеме Чыгыш булган. Алтынчысы аларның кайда булганын, сәгатьнең ничә булуын хәбәр итеп торгач, аны Урын-вакыт дип йөрткәннәр. Менә шулай алар бер-берсенә исем кушып бетергәннәр. Ләкин бер акыллы карт әйткән:

-Сезнең исемнәрегез инде бар, ләкин фамилиягез юк бит, - дигән.Болар уйга батканнар. Һәм бер фикергә килеп, үзләренә фамилияне " Килеш" дип сайлаганнар.Шуннан бирле аларның фамилияләре һәм исемнәре:

- *Баш килеш*
- *Иялек килеше*
- *Юнәлеш килеше*
- *Төшем килеше*
- *Чыгыш килеше*
- *Урын-вакыт килеше булган.*

**Гәрәева Назлыгөл,5 нче сыйныф**

### Куян белән Төлке.

Борын-борын заманда яшәгән, ди, Төлке белән Куян. Алар бик дус, тату яшәгәннәр, ди. Куянның да, Төлкенең дә койрыклары зур, матур булган. Менә салкын кыш житкән. Төлкегә бик салкын була башлаган. Ул Куян дустыннан ярдәм сорый башлаган:

-Дустым, миңа язга кадәр генә койрыгыңны биреп торчы, синекен үземнең койрыгыма өстәп куйсам, зур койрык белән миңа бик җылы булыр иде, - дигән.

Куян дустын кызганган һәм ризалашкан. Әмма Төлке бик хәйләкәр булган шул. Куянның койрыгын яз житкәч тә, җәй дә, көз дә кире бирмәгән. Әлегә кадәр аның койрыгы белән йөри икән. Менә шуңа күрә Төлкенең койрыгы бик озын, йомшак, матур, ә Куянныкы кечкенә булып калган. Бу хәлләрдән соң Куян үзенә бик зур сабак алган һәм Төлке белән дус булудан туктаган.

-Андыйлардан ераграк йөрүең хәерлерәк ! - дип, әле дә булса ул Төлкедән качып йөри , ди.

**Һадиева Рамилә,5 нче сыйныф**